**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
СТАРОУТЯМЫШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423105,Черемшанский район, с.Старый
Утямыш, ул.Мусы Джалиля, дом 52

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИСКЕ ҮТӘМЕШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423105,Чирмешән районы Иске Үтәмеш
авылы, Муса Җәлил урамы, 52 нче йорт

тел./факс 8-84396-2-37-16 email: Sut.Cmn2@tatar.ru

**№5** **2018елның 28мартыннан**

# КАРАР

## 2018 елның язгы чорында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге территориясендә 4 тонна һәм аннан күбрәк йөк күтәрүчәнлеге булган механик транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында

2007 елның 8 ноябрендәге 257 –ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» гы Федераль закон нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлеге» Уставына таянып КАРАР БИРӘМ:

1.Иске Үтәмеш авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 1 апреленнән 1 майга кадәр юл катламнарын саклап калу максатыннан ТР Чирмешән районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге торак пунктлары эчендә 4 тонна һәм аннан да күбрәк йөк күтәрүчәнлеге булган механик транспорт чаралары хәрәкәте тыела.

2. Чикләү җәмәгать транспортына, хезмәт машиналарына кагылмый«01», «02» , «03», «04»; автотранспорт ,чүп ташучы, почта автомобильләре, авария хезмәтләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәтләре автотранспорты, беренче чиратта кирәкле азык-төлек продуктларын (икмәк, он, сөт, атланмай, шикәр, тоз, ит, йомырка, чәй, балалар туклануы), хайваннар, дару препаратлары, орлык фонды, ашламалар ташу өчен транспорт чаралары.

3. Әлеге карарны җирлекнең барлык торак пунктларында һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә кирәк. http://cheremshan.tatarstan.ru/rus/index.htm

4.Әлеге карар пунктларын бозган очракта, гаепле затлар административ җаваплылыкка һәм штрафка тартылачак.

Чирмешән районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р. С. Мингулов